# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Уразлы торак пунктында

29 нчы октябрь 2023 ел №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына нигезләнеп Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Уразлы торак пунктында гражданнар җыены

**Карар кабул итте:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Уразлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән мобилизациялəнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2200 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- зиратны төзекләндерү;
- электр баганалары һәм яктырткычлар урнаштыру;
- территорияне төзекләндерү (күпернең перильле коймасын буяу);

3. Әлеге карарны Олы Җәке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 10 көн дәвамында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы Ф. А. Фәйзуллина